| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ШУБАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020г. № 14

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Шубан авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, ШУБАН авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ.:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 92 номерлы карары( 29.04.2019 елдагы 100 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның 14.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп: "14.2. Йорт хайваннары һәм кош-корт хуҗалары "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"27.12.2018 ел, № 498-ФЗ Федераль законның 13 статьясында күрсәтелгән таләпләрне үтәргә тиеш.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Шубан авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов.